**Глава Абалачевского сельского поселения Менделеевского муниципального района Республики Татарстан**
ул. Центральная д. 35, помещ.1, д. Абалачи
Менделеевский район, 423657

**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Башлыгы**
Үзәк урамы, 35, бина 1, Абалач авылы,
Менделеевск районы, 423657

тел./факс (85549)3-65-49 Email: Abal.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 ноябрь 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елның 27 ноябрендә 17 сәгать 30 минутка Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Менделеевск районы, Тагай авылы, Подлесная урамы, терлекче йорты.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: «2026 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә, ә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия Армиясе сафларына сроклы хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, көндезге уку формасындагы студентларны түләүдән азат итәргә һәм алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?”:

«1. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: (юлларны кардан чистарту, үлән чабу, урам яктырткычларын алыштыру, Абалач авыл җирлегенең

Тагай авылы территориясендә 3данә мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру.)»?

«Риза» «Каршы»

3. Әлеге карарны Тагай авылында мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Абалач авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

Абалач авыл җирлеге башлыгы И.Н. Әкбәров